ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2019 г.Лениногорск № 2162

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 31.08.2018 ел, № 1276 карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексына туры китерү максатларында «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 августындагы 1276 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлегендәге 2 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«База оклады (төп вазыйфаи оклад), хезмәт хакының төп ставкасы - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керә торган эшче яисә хезмәткәр һөнәре яисә хезмәткәр вазыйфалары буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы дәүләт яисә муниципаль учреждение хезмәткәренең хезмәт хакы ставкасы.»;

I бүлекнең 2 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оклад (вазыйфаи оклад) - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең хезмәтенә түләүнең беркетелгән күләме.».

2.Әлеге карарны «Лениногорские вести» рәсми публикатор-газетасында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, гражданнарны күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына В. В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И. Р. Хәйбрахманов
5-44-72